
**15 МАЙ – УДМУРТИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНӘ 105 ЕЛ**

# Булачак эш урынымны төштә күрдем

**Мин китапханәне төштә күрдем. Имеш рәт-рәт булып тезелгән чиксез киштәләр яныннан йөрим. Кулым белән китап тышлыкларын сыйпыйм. Уянып киттем һәм шул чагында китапханәдә эшләргә теләгәнемне аңладым.**



Бу вакытта мин Удмурт дәүләт университетын тәмамлап, тәрҗемәче, француз теле укытучысы дипломын алган идем. Мәктәптә, балалар бакчасында эшләп карарга өлгердем, әмма җаным башка нәрсәне тели иде. Бернилә айдан соң мине Республика милли китапханәсенә эшкә чакырдылар. Студент чагында нәкъ шушы китапханәдә шөгыльләнергә ярата идем. Аның түшәмнәре биек. Диварларындагы бизәкләренә, бәллүр люстраларына, зур тәрәзәләренә, келәмнәренә сокланып карый идем. Уку залында тирән тынлык тора иде. Китаплар эзләгәндә, таблода санның януы миңа ошый иде. Димәк, мин эзләгән китаплар табылган. Ә кич белән өстәл лампасы эш атмосферасы тудыра. Шушы тылсымлы мохиттә эшләячәгем мине бик сөендерде.

Беренче эш урыным вакытлы матбугат бүлеге булды. Башта миңа газета-журналларның кайда урнашканын истә калдыру авыр булды. Эшнең рәтенә төшенгәч, мин кирәкле басманы җиңел генә табудан тыш, хәтта кайсы санның югалганын, кайсы битләре ертылганын да әйтә ала идем. Заманча күчерү (ксерокс) техникалары барлыкка килгәч, газета-журналларны ертып алу очраклары кимеде. Кайвакытта ксерокс аппаратына шактый чират җыела. Барлык заявкаларны бетереп, ял итәргә утыруга: «Ксерокс ясарга мөмкинме?» – дип тагын дәшәләр.

Шушы катның икенче яртысын социаль-икътисади әдәбият бүлеге биләп тора. Монда кызлар укучыларга кирәкле китапларны шифр һәм инвентарь номеры буенча эзлиләр иде. Китаплар лифтларда күтәрелә. Алар тавыш чыгарып, берсе аска, икенчесе өскә юнәлә. Йөк лифты китапханәгә экскурсиягә килүчеләрдә дә кызыксыну уята иде. Айга бер тапкыр, ягъни һәр айның соңгы чәршәмбесендә санитар көн игълан ителә. Хәзерге вакытта да бу көн сакланып калды. Бу көнне без традиция буенча җыештырабыз һәм туган көннәрне билгеләп үтәбез. Кемдер җыештырган арада туган көн ияләре төшке ашка әзерләнә башлыйлар. Китапханәдә таралган хуш исләр борынны кытыклый.

2000 еллар башында компьютерлар кулланышка керә башлады. Китапханәдә интернет-класс барлыкка килде, теркәү бүлегендә укучыларны электрон рәвештә язуга күчтек. Мин хезмәттәшләремнең бу могҗизалы техника белән эшли белүләрен ак көнләшү белән күзәтә идем. Бәхеткә каршы, укучыларны теркәү һәм статистика бүлегендә вакансия барлыкка килде һәм мин яңа коллективка күчтем. Иртәнге сәгать унга язылырга яки укучы билетын озайтырга теләүчеләрдән озын чират тезелә. Кайвакыт без бу эшне өчәүләп башкардык: беребез укучылар турындагы мәгълүматны базага кертте, икенчебез фотосын ябыштырып, укучы билеты ясады, өченчебез исәпләүләр ясады. Ничек кенә тырышып эшләсәк тә, чират беркайчан да бетмәде. Шуңа күрә без үз эшебезне беркайчан да туктатып булмый торган «Мартен миче» эше белән чагыштырып шаярта идек.

Китапханәгә шимбә көннәрендә керү аеруча «күңелле» була иде. Китапханә ачылуын көтеп, фойеда җыелган халык арасыннан: «Үткәрегез мине, мин монда эшлим», – дип, көчкә үтә идек. Ике гардеробта да киемнәрне эләргә урын бетә, шуңа күрә тапкыр кешеләр киемнәрен машинада ук салып калдыра иделәр. Мәгълүмати технологияләр алга киткәч, укучылар агымы әкренләп кими башлады. Хәзер китапханә алдында яңа бурыч – кулланучыларны ничек җәлеп итәргә? Бу бөтенләй башка эшчәнлек төре. Монда идеяләрнең илһамчысы һәм бик таләпчән оештыручы, укучыларга хезмәт күрсәтү буенча директор урынбасары Галина Шантурова булды. Ул бик белемле, даими үсештә, йөз адым алга карап эш йөртә. Башта планеркадан аптырашка калып чыга идек. Ләкин әкренләп, бездән нәрсә таләп ителгәнен аңлый башладык һәм кирәкле нәтиҗәләргә ирештек. Төрле категория укучыларның ихтыяҗларын исәпкә алып, чаралар, семинарлар оештыра башладык. Шул вакыттан бирле «акция» сүзе безнең сөйләмгә нык-лап керде. 2009 ел нәтиҗәләре буенча коллектив җыелышында миңа «Китапханәнең укучысы бул» проекты кысаларында акцияләр оештырган һәм үткәргән өчен «Ел китапханәчесе» дипломы тапшырдылар. Бу хәл көтелмәгәндә булды, әмма хезмәтне бәяләүләре күңелне үстерде.

Безнең бүлекнең бурычлары яңа китап укучыларны яздыру һәм аларга мәгълүматлар бирү генә түгел, ә исәп-хисап алып барудан да гыйбарәт иде. Бүлек мөдире буларак, нәкъ менә мин безгә ничә укучы язылды, алар безгә ничә тапкыр килделәр, ничә китап укыдылар – барысының да хисабын алып бардым. Башта миңа бу эш Кытай грамотасы кебек тоелса да, соңрак бу эш күңелемә рәхәтлек бирә башлады. Китапханәнең төп бинасы төзекләндерүгә ябылгач, безнең бүлекләр төрле кечкенә мәйданчыкларга таратылды. Бу безгә якын-тирәдәге йортларда яшәүчеләр белән дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга ярдәм итте. Без аларга кызыклы китаплар тәкъдим иттек, ә алар үз чиратында, укыган китапларыннан алган тәэсирләре белән уртаклаштылар. Мөгаен, бу укучылар безнең ремонтланган бинага күченүебезне теләмәгән бердәнбер кешеләр булганнардыр.

Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан китапханәдә «Иң яхшы бәйрәм бизәлеше»нә конкурс игълан иттеләр. Китапханәгә килүчеләр иң беренче минем бүлеккә керәләр. Аны матур итеп бизәү өчен уйлана башладым, төнге тыныч йокылар бетте. Ниһаять, минем беренче фотозонам – «хюгге» стилендәге камин «туды». Шулай итеп, Яңа ел бәйрәмнәрендә фотозонаны бизәү традициягә керде. Ел саен мин безгә килүчеләрне гаҗәпләндерергә, сөендерергә тырышам. Бизәү белән кичләрен шөгыльләнәм, эштә озак тоткарланган чакларым да күп. Ләкин болар барысы да хезмәттәшләремнең, укучыларның күңелен күтәрү өчен эшләнә.

Шулай итеп минем егерме ел «передовой»да үтте: теркәлү, яңадан теркәлү, мәгълүмат бирү, айлык отчетлар... Әмма тора-бара күңел яңалык тели башлады. Мин китапханә-мәгълүмат ресурсларын формалаштыру бүлегенә күчтем. Кайберәүләр минем карарыма гаҗәпләнделәр. «Үкенмисеңме?» – дип сораучылар да булды. Ә мин шкаф артында утырып, яңа күнекмәләрне үзләштердем. Укучыларны теркәү урынына китап базарын, әдәби премия лауреатларын, укучыларның бәяләмәләрен өйрәндем. Бу минем яраткан китапханәмдә үткән юлым, ләкин миңа омтылырга, өйрәнергә, үсәргә урын бар әле.

Гөлнара ВЕСЕЛКОВА,
Ижау шәһәре.